ИНСПЕКЦИЯ
ГОСУДАРСТВЕННОГО
СТРОИТЕЛЬНОГО НАДЗОРА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШЕН
КҮЗӘТҮ ИНСПЕКЦИЯСЕ

ПРИКАЗ БОЕРЫК

__26.01.2018________ Казан № __09______

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 елның 04 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең норматив хокукый актларын федераль законнарга яраштыру максатларында

БОЕРЫК БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 елның 04 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 26 июлендәге 48 номерлы, 2017 елның 06 апрелендәге 21 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына кертелә торган, кушымтада бирелгән үзгәрешләрне расларга.

2. Әлеге боерыкның гамәлдә булу чоры 2018 елның 1 гыйнварыннан башлап барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге боерыкның Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 25 октябрендәге 1294 номерлы карарының 2 пунктын исәпкә алып кулланылуын билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең хокук идарәсе юридик бүлегенә бу боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

5. Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең җыелма анализ бүлегенә әлеге боерыкны Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең рәсми сайтында урнаштырырга.

6. Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Башлык В.А. Кудряшов

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2013 елның 04 декабрендәге 94 номерлы боерыгы белән (Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең 2016 елның 26 июлендәге 48 номерлы, 2017 елның 06 апрелендәге 21 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәү буенча административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр**

1 бүлектә:

1.2 пунктының сигезенче абзацын төшереп калдырырга;

1.3 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт төзелеш күзәтчелеге түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 1 (1 өл.), 1 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Арбитраж процессуаль кодексы (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 30, 3012 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Шәһәр төзү кодексы (алга таба – РФ ШрК) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2005, № 1 (1 өл.), 16 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Куркынычлы җитештерү объектларының сәнәгый куркынычсызлыгы турында» 1997 елның 21 июлендәге 116-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1997, № 30, 3588 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында» 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 1999, № 14, 1650 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектлары (тарихи һәм мәдәни ядкәрләре) турында» 2002 елның 25 июнендәге 73-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 73-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 26, 2519 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2002, № 52 (1 кисәк), 5140 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2004, № 31, 3215 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 19, 2060 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент» 2008 елның 22 июлендәге 123-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2008, № 30 (1 кисәк), 3579 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контрольлеген (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2008, № 52 (1 к.), 6249 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 261-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2009, № 48, 5711 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 384-ФЗ номерлы федераль закон) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 1, 5 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеге турында» 2006 елның 1 февралендәге 54 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 54 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2006, № 7, 774 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Капиталь төзелеш объектларын төзүне, үзгәртеп коруны һәм капиталь төзекләндерүне гамәлгә ашырганда төзелеш контролен уздыру тәртибе турында» 2010 елның 21 июнендәге 468 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2010, № 26, 3365 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Аларны куллану нәтиҗәсендә «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» федераль законы таләпләренең үтәлүе зарури нигездә тәэмин ителә торган илкүләм стандартлар һәм кагыйдәләр җыелмалары (мондый стандартларның һәм кагыйдәләр җыелмаларының өлешләре) исемлеген раслау турында» 2014 елның 26 декабрендәге 1521 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2015, № 2, 465 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан

документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карары) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016, № 35, 5326 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар белдерүе һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә башкарма документация составына һәм аны алып бару тәртибенә карата таләпләрне һәм эшләрне, конструкцияләрне, инженер-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актларына белдерелә торган таләпләрне раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 06 мартында 9050 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда тикшерүләр уздыру һәм төзелгән, үзгәртеп корылган, төзекләндерелгән капиталь төзелеш объектларының техник регламентлардагы, бүтән норматив хокукый актлардагы, проект документларындагы таләпләргә (нормаларга һәм кагыйдәләргә) ярашуы турында бәяләмәләр бирү тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1129 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 06 мартында 9053 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 2006 елның 26 декабрендәге

1129 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 15, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда эшләрне формалаштыру һәм алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2006 елның 26 декабрендәге 1130 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 05 мартында 9009 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 2006 елның 26 декабрендәге 1130 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 13, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Экологик, технологик һәм атом күзәтчелеге буенча федераль хезмәтнең «Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда, капиталь төзекләндергәндә эшләр башкаруны исәпкә алу буенча гомуми һәм (яисә) махсус журнал алып бару тәртибен раслау һәм гамәлгә кертү турында» 2007 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2007 елның 06 мартында 9051 номеры белән теркәлгән) (алга таба – 2007 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы Ростехнадзор боерыгы) (Федераль башкарма хакимият органнары норматив актлары бюллетене, 2007, № 14, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (РФ Юстиция министрлыгында 2009 елның 13 маенда 13915 номеры белән теркәлгән) (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

РФ Төзелеш һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының «Төзелешкә рөхсәт формасын һәм объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт формасын раслау турында» 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы (алга таба – Россия Төзелеш министрлыгының 2015 елның 19 февралендәге 117/пр номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе Законнар җыентыгы, 2013, № 47, 6117 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Техник җайга салу һәм метрология буенча федераль агентлыкның «Стандартлаштыру өлкәсендә аларны куллану нәтиҗәсендә «Биналарның һәм корылмаларның куркынычсызлыгы турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы федераль закон таләпләрен үтәү ирекле нигездә тәэмин ителә торган документлар исемлеген раслау турында» 2015 елның 30 мартындагы 365 номерлы боерыгы (Норматив, методик һәм типик проект документлары турында мәгълүмат бюллетене, 2015, № 5, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе мәсьәләләре» 2007 елның 12 ноябрендәге 622 номерлы карары (алга таба – 622 номерлы ТР МК карары) («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2007, № 43, 1707 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Төзелеше өчен төзелешкә рөхсәтләр бирү таләп ителми торган объектлар исемлеген раслау турында» 2011 елның 24 июнендәге 1038-р номерлы боерыгы («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимияте органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2011, № 33, 1617 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып).»;

1.5 пунктка түбәндәге эчтәлекле икенче абзац өстәргә:

«Дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештырганда куркынычка юнәлдерелгән якын килү алымы кулланыла.»;

1.6 пунктка түбәндәге эчтәлекле унынчы абзац өстәргә:

«Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру кысаларында тикшерүләр уздырганда социаль, инженер һәм транспорт инфраструктурасы объектларының һәм әлеге Регламент күздә тоткан тәртиптә күрсәтелә торган хезмәтләрнең инвалидлар өчен үтемле булуын тәэмин итү буенча дәүләт контроле (күзәтчелеге) гамәлгә ашырыла.»;

1.7 пунктында:

8 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзелешне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыручы заттан төзелешне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән затлар белән шартнамәләрне, үзкөйләнешле оешма (алга таба – ҮКО) әгъза булып торуны яисә ҮКО әгъза булу зарурлыгы булмавын раслаучы документларны тапшыруны таләп итү;»;

10 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) түләүсез нигездә, шул исәптән электрон рәвештә, Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән исемлеккә кертелгән документларны һәм (яки) мәгълүматны шушы документлар һәм (яки) мәгълүмат белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомство буйсынуындагы оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә соратырга һәм алырга;»;

2 бүлектә:

2.8 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектлары һәм аларга беркетелгән куркыныч категорияләре турында түбәндәге мәгълүматлар:

а) төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектының атамасы, адресы һәм төзелү, үзгәртеп корылу этабы;

б) төзелешкә рөхсәт реквизитлары (датасы һәм номеры);

в) юридик затның тулы атамасы, шәхси эшкуар - төзүченең фамилиясе, исеме һәм атасының исеме (булган очракта);

г) капиталь төзелеш объектының куркыныч категориясе.»;

3 бүлектә:

беренче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата белдерелә торган зарури таләпләр исемлеге, тиешле таләпне билгели торган норматив хокукый актларны күрсәтеп, 2 нче таблицада китерелде.»;

түбәндәге эчтәлекле 3.2-3.4 пунктлары өстәргә:

«3.2. Юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан зарури таләпләр бозылуны кисәтү, зарури таләпләр бозылуга китерә торган сәбәпләрне, факторларны һәм шартларны юкка чыгару максатларында Инспекция ел саен үзе раслаган бозуларны профилактикалау программасы нигезендә зарури таләпләр бозылуны профилактикалау буенча чараларны гамәлгә ашыра.

3.3. Зарури таләпләр бозылуны профилактикалау максатларында Инспекция 294-ФЗ номерлы федераль законның 8.2 статьясының 5-7 өлешләрендә билгеләнгән очракларда һәм тәртипкә ярашлы рәвештә зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү бирә һәм юридик затка, шәхси эшкуарга зарури таләпләр үтәлешен тәэмин итү буенча чаралар күрергә һәм бу хакта мондый кисәтүдә билгеләнгән чорда Инспекциягә хәбәр итәргә тәкъдим итә.

3.4. Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтү төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүгә ризасызлыклар тапшыру һәм аларны Инспекция тарафыннан карау, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүнең үтәлүе турында хәбәр итү РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карарына ярашлы рәвештә гамәлгә ашырыла.»;

4 бүлекнең 3 таблицасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

**«3 таблица – Тикшерү үткәрүнең максатларына һәм бурычларына ирешү өчен юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар исемлеге**

| Тикшерү уздырганда юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан тапшырыла торган документлар | Документ рәвешен билгели торган норматив хокукый акт |
|---|---|
| 1. Тулы күләмендә проект документациясе, ә төзелешнең, үзгәртеп коруның аерым этабына рөхсәт бирелгән очракларда, – төзүче, техник заказчы тарафыннан расланган, төзелешнең тиешле этабын гамәлгә ашыру өчен зарури күләмдә. | - |
| 2. Җирлеккә кызыл линияләрдән чигенү линияләрен чыгару турында документ | - |
| 3. Үзкөйләнешле оешмада әгъза булып торуны яисә үзкөйләнешле оешмада әгъза булып тору зарурлыгы булмавын раслаучы документлар | - |
| 4. Эшләрнең гомуми һәм (яисә) махсус журналлары | 2007 елның 12 гыйнварындагы 7 номерлы Ростехнадзор боерыгы |
| 5. Башкарма документация, шул исәптән: | 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы |
| 5.1. Капиталь төзелеш объектының геодезик бүленеш нигезен таныклау акты | 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы |
| 5.2. Җирлектә капиталь төзелеш объекты күчәрләрен бүлү акты | 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы |

| | |
|---|---|
| 5.3. Яшерен, капиталь төзелеш объектының куркынычсызлыгына йогынты ясый торган һәм төзелеш, үзгәртеп кору технологиясенә ярашлы рәвештә башкарылуына карата контрольлек башка эшләрне башкарудан соң уздырыла алмый торган эшләрне таныклау актлары (алга таба – яшерен эшләр). Таныкланырга тиешле яшерен эшләр исемлеге проект документациясендә билгеләнә. | 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы |
| 5.4. Алар буенча төзелеш контролен уздыру процессында ачыкланган җитешсезлекләрне сүтмичә яисә башка төзелеш конструкцияләренә һәм инженер-техник тәэмин челтәрләре өлешләренә зыян китермичә мөмкин булмаган җаваплы төзелеш конструкцияләрен таныклау актлары (алга таба – җаваплы конструкцияләр). Таныкланырга тиешле җаваплы конструкцияләр исемлеге проект документациясендә билгеләнә. | 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы |
| 5.5. Алар буенча төзелеш контролен уздыру процессында ачыкланган җитешсезлекләрне сүтмичә яисә башка төзелеш конструкцияләренә һәм инженер-техник тәэмин челтәрләре өлешләренә зыян китермичә мөмкин булмаган инженер-техник тәэминат челтәрләре өлешләрен таныклау актлары. Таныкланырга тиешле инженер-техник тәэминат челтәрләре өлешләре исемлеге проект документациясендә билгеләнә. | 2006 елның 26 декабрендәге 1128 номерлы Ростехнадзор боерыгы |
| 6. Капиталь төзелеш объектын төзүгә, үзгәртеп коруга эш документациясе, – натурада башкарылган эшләрнең төзүне гамәлгә ашыручы зат тарафыннан эшләнгән эш документациясенә туры килүе турындагы язулары белән. Төзүне гамәлгә ашыручы зат исеменнән мондый язуларны күрсәтелгән затның вәкиле вәкиллекне раслаучы документ нигезендә кертә. | - |
| 7. Башкарма документация составына шулай ук түбәндәге материаллар да кертелә:<br>- башкарма геодезия схемалары;<br>- инженер-техник тәэминат челтәрләре өлешләренең башкарма схемалары һәм профильләре;<br>- техник җайланмаларны сынау һәм кулланып карау актлары;<br>- төзелеш контролен башкарганда башкарылган эшләргә уздырылган экспертизаларның, | - |

| | |
|---|---|
| тикшерүләрнең, лаборатор һәм башка төрле сынауларның нәтиҗәләре;<br>- кулланыла торган төзелеш материалларының (эшләнмәләренең) сыйфатына контроль ясалуны раслаучы документлар;<br>- проект чишелешләрен фактта үтәүне чагылдырган башка төрле документлар | |
| 8. Төзелешне оештыру проекты, биналарны һәм корылмаларны, инженер һәм транспорт коммуникацияләрен торгызу эзлеклелеген билгели, төзелешнең календарь планында билгеләнгән төзелешне тәмамлау чорларының, капиталь төзелеш объектларын яисә аларның аерым элементларын торгызганда технологик эзлеклелекнең, төзелешнең календарь планы, Инспекция вазыйфаи затының капиталь төзелеш объектына тикшерүләр уздыру программасын эшләү өчен кирәкле әзерлек чорын да (төп һәм ярдәмче биналарның һәм корылмаларның төзелү чорларын һәм эзлеклелеген, төзелеш этапларын бүлеп чыгаруны) кертеп, үтәлүен тәэмин итә торган оештыру-технологик схема | - |
| 9. Төзелеш контролен уздырганда һәм дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда ачыкланган бозуларны бетерү турында актлар | - |
| 10. Норматив хокукый актларда каралган, әйләнә-тирә мохитне саклау өлкәсендә Россия Федерациясе законнары таләпләре, янгын куркынычсызлыгы һәм халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге таләпләре, шулай ук энергетика нәтиҗәлелеге һәм капиталь төзелеш объектының кулланыла торган энергетика ресурсларын исәпкә алу җайланмалары белән тәэмин ителү таләпләре үтәлешен раслый торган документлар | - |
| 11. Административ хокук бозулар турында эшләр буенча карарларның үтәлүен раслаучы документлар (булган очракта) | - |
| 12. Төзелешне гамәлгә ашыру өчен җәлеп ителгән затлар белән техник заказчы функцияләрен башкаруга (булган очракта), төзелеш контролен гамәлгә ашыру буенча эшләрне башкаруга (булган очракта), авторлык күзәтчелегенә (булган очракта) шартнамәләр | - |
| 13. Төзелеш контролен гамәлгә ашыру өчен | - |

| | |
|---|---|
| җаваплы затны билгеләү турында, эшләр башкарылуы өчен җаваплы затны билгеләү турында, төзүче яисә техник заказчы тарафыннан проект документациясен раслау турында боерыклар | |

5 бүлектә:

5.2 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.2. Административ процедураны башлап җибәрү өчен әлеге Регламентның 2.14 пунктындагы 1 пунктчасында күрсәтелгән факт булуы (Инспекциягә төзүчедән, техник заказчыдан, теркәлүче документлары белән бергә, эшләрне башлау турында хәбәр килүе (алга таба – эшләр башлану турында хәбәр)) нигез булып тора.

Административ процедура түбәндәге административ гамәлләрне үз эченә ала:

- эшләр башлану турында хәбәрне кабул итү, теркәү, карау;

- дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру (гамәлгә ашырудан баш тарту) турында карар кабул итү, дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затларны билгеләү;

- вазыйфаи затларны билгеләү турында боерык һәм төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектына куркыныч категориясе бирелү турында боерык әзерләү;

- капиталь төзелеш объектына карата дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча Инспекция эше формалаштыру, аңа номер бирү (алга таба – күзәтчелек эше);

- тикшерүләр уздыру программасын эшләү.»;

5.6 пунктта:

икенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) яисә территориаль орган бүлеге башлыгы дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен җаваплы вазыйфаи затны (вазыйфаи затларны) билгели, бердән артык вазыйфаи зат билгеләнгән очракта, алар арасыннан төркем җитәкчесен билгели һәм вазыйфаи затка (төркем җитәкчесенә) вазыйфаи затларны билгеләү турында боерык проекты, төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектына куркыныч категориясе бирү турында боерык проекты әзерләргә куша.»;

дүртенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Гамәлнең нәтиҗәсе: дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру (гамәлгә ашырудан баш тарту) турында карар кабул итү, җаваплы итеп билгеләнгән территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары), территориаль орган бүлеге башлыгы, җаваплы башкаручы, төркем җитәкчесе; төркем җитәкчесенә (җаваплы башкаручыга) вазыйфаи затларны билгеләү турында боерык проекты, төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектына куркыныч категориясе бирү турында боерык проекты әзерләү йөкләмәсе.»;

«Дәүләт төзелеш күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыруга әзерләү» административ процедурасында «Вазыйфаи затларны билгеләү турында боерык әзерләү» бүлекчәсендә:

бүлекчә аталышын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Вазыйфаи затларны билгеләү турында боерык һәм төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектына куркыныч категориясе бирелү турында боерык әзерләү»;

түбәндәге эчтәлекле 5.7.1 пунктын өстәргә:

«5.7.1. Җаваплы зат (төркем җитәкчесе) төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектына куркыныч категориясе бирү турында боерык проекты әзерли, аны бүлек башлыгы, территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) белән килештерә һәм имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) җибәрә.

Төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашырганда төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектларын куркыныч категориясенә кертү критерияләре РФ Хөкүмәтенең 54 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру турында нигезләмәдә билгеләнгән.

Капиталь төзелеш объектларын төзегәндә, үзгәртеп корганда федераль законнарда һәм аларга туры китереп кабул ителә торган Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актларында билгеләнгән таләпләрнең юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар тарафыннан үтәлмәү ихтималы аркасында потенциаль тискәре нәтиҗәләрнең авырлык критериясенә туры китереп, мондый объектлар түбәндәге куркыныч категорияләренә кертелә:

бик куркыныч – җәмәгать биналары һәм корылмалары, күпфатирлы торак йортлар, юлүткәргечләр, тоннельләр, күперләр һәм эстакадалар, шулай ук 20 метрдан 100 метрга кадәр торыклы капиталь төзелеш объектлары;

шактый куркыныч – җитештерү биналары;

уртача куркыныч – әлеге пунктның дүртенче һәм бишенче абзацларында күрсәтелмәгән капиталь төзелеш объектлары.

Төрле куркыныч категорияләренә карый торган ике һәм аннан күбрәк капиталь төзелеш объекты төзелешенә рөхсәт бирелгән очракта, куркыныч категорияләре һәр капиталь төзелеш объектына карата аерым билгеләнә.

Үтәү вакыты: йөкләмә алынган көннән соңгы бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектына куркыныч категориясе бирү турында боерык.»;

5.9 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.9. Шушы Регламентның 5.3 пунктында күрсәтелгән эшләр башлану турында хәбәр нигезендә вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе) әлеге Регламентка 5 нче кушымтага туры китерелгән формада тикшерүләр программасын эшли.

Тикшерүләр программасы капиталь төзелеш объектының конструктив һәм башка төрле үзенчәлекләрен, капиталь төзелеш объектларын яки аларның аерым элементларын торгызганда эшләр башкаруның технологик эзлеклелеген, алга таба эксплуатацияләү шартларын, шулай ук техник регламентлардагы, башка норматив хокукый актлардагы һәм проект документларындагы таләпләргә туры китереп исәпкә алынырга тиешле башка факторларны да исәпкә алып эшләнә.

Тикшерүләр программасы төзелә, үзгәртеп корыла торган тиешле капиталь төзелеш объектының куркыныч категориясе өчен капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору чоры өчен түбәндәге санда тикшерүләрне исәпкә алып төзелә:

а) бик куркыныч категориясе өчен – иң күбе 12 тикшерү;

б) шактый куркыныч категориясе өчен – иң күбе 10 тикшерү;

в) уртача куркыныч категориясе өчен – 7дән артмаган тикшерү.

Тикшерүләр программасы вазыйфаи затларны билгеләү турында боерык үтәлеше өчен җаваплы зат тарафыннан килештерелә һәм Инспекциянең территориаль органы җитәкчесе тарафыннан раслана.

Тикшерүләр программасында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:

а) капиталь төзелеш объекты төзүне оештыруның РФ ШрК 48 статьясының 12 өлешендәге 6 пунктында каралган проектына (алга таба – капиталь төзелеш объекты төзүне оештыру проекты) туры китереп билгеләнә торган, тикшерелергә тиешле эшләрнең аталышы;

б) һәр тикшерүнең предметы;

в) капиталь төзелеш объектын төзүне оештыру проекты белешмәләренә нигезләнеп ачыклана торган һәр тикшерүне уздыруның якынча датасы;

г) һәр тикшерүне уздыру буенча дәүләт төзелеш күзәтчелеге органы вазыйфаи затының чама белән сарыф ителгән вакыты;

д) тикшерүләр программасында каралган, тикшерүләрне уздырганда тапшырылырга тиешле документлар;

е) тикшерүләр программасында каралганча тикшерүләрне уздырганда зарури катнашырга тиешле вазыйфаи затлар яисә төзүченең, техник заказчының хезмәткәрләре яки төзүче яки техник заказчы белән төзелгән шартнамә нигезендә төзелешне гамәлгә ашыручы затлар;

ж) төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектының куркыныч категориясе.

Тикшерүләр программасы ике нөсхәдә төзелә, шуларның берсе Инспекциянең күзәтчелек эшендә кала, икенчесе төзүчегә яки техник заказчыга (аларның вәкаләтле вәкиленә) җибәрелә (тапшырыла).

Төзүченең яисә техник заказчының вәкиле тикшерүләр программасы нөсхәсен кулга алудан (имзалаудан) баш тарткан очракта, документ кулга тапшыру тамгасы белән почта аша заказлы хат итеп җибәрелә.

Үтәү вакыты: Эшләр башлану турында хәбәр Инспекциягә (территориаль органнарга) килеп ирешкән көннән башлап җиде эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: эшләнгән һәм төзүчегә яисә техник заказчыга тапшырылган (җибәрелгән) тикшерүләр программасы.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.9.1 пунктын өстәргә:

«5.9.1. Капиталь төзелеш объектын төзегәндә, үзгәртеп корган чорда тикшерүләр күләме иң күбе 2 тикшерүгә арттырылырга мөмкин, түбәндәге очракларда:

а) кысынкы шәһәр төзелеше шартларында капиталь төзелеш объекты төзелгәндә, үзгәртеп корылганда (проект документациясенә туры китереп);

б) капиталь төзелеш объекты катлаулы инженер-геологик шартларда төзелгәндә, үзгәртеп корылганда (проект документациясенә туры китереп);

в) гомуми мәйданы 20 000 кв. метрдан артып китә торган капиталь төзелеш объекты төзелгәндә, үзгәртеп корылганда.

Капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору чорында тикшерүләр күләме бик куркыныч категориясе бирелгән капиталь төзелеш объектына карата 24 тикшерүгә кадәр, шактый куркыныч категориясе бирелгән капиталь төзелеш

объектына карата 20 тикшерүгә кадәр, уртача куркыныч категориясе бирелгән капиталь төзелеш объектына карата 14 тикшерүгә кадәр тиешенчә арттырылырга мөмкин, түбәндәге очракларда:

а) капиталь төзелеш объектын төзүне, үзгәртеп коруны гамәлгә ашыручы юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар бер календарь елы эчендә 3 һәм аннан күбрәк мәртәбә РФ КоАП 6.3, 8.1 һәм 9.4 статьяларында, 9.5 статьясының 1-3 өлешләрендә, 9.5.1 статьясында, 9.16 статьясының 3 өлешендә, 19.4 статьясының 1 өлешендә, 19.5 статьясының 6 һәм 15 өлешләрендә, 19.6, 19.7 һәм 19.33 статьяларында һәм 20.4 статьясының 1, 2, 6, 6.1 һәм 9 өлешләрендә каралган хокук бозулар өчен административ җаваплылыкка тартылганда;

б) уңай экспертиза бәяләмәсе алган проект документациясендә төзелешне оештыру проекты белән каралган капиталь төзелеш объекты төзхнең, үзгәртеп коруның яки аны консервацияләүнең, төзелешен туктатып торуның чорлары 6 айдан артыгракка бозылганда.

Вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе) Инспекция башлыгы урынбасарына капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору чорында тикшерүләр санын арттыру турында карар кабул итү өчен тиешле нигезләр барлыкка килүе турында хәбәр итә.

Инспекция башлыгы урынбасары, тикшерүләр санын арттыру турында карар кабул ителгән очракта, вазыйфаи затка (төркем җитәкчесенә) капиталь төзелеш объектын төзү, үзгәртеп кору чорына тикшерүләр санын арттыру турында боерык проектын (алга таба – тикшерүләр санын арттыру турында боерык) әзерләү йөкләмәсен бирә.

Вазыйфаи зат (төркем җитәкчесе) тикшерүләр санын арттыру турында боерык проекты әзерли, аны бүлек башлыгы, территориаль орган җитәкчесе (җитәкче урынбасары) белән килештерә һәм имза салу өчен Инспекция башлыгына (башлык урынбасарына) җибәрә.

Үтәү вакыты: йөкләмә алынган көннән соңгы бер эш көне эчендә.

Гамәлнең нәтиҗәсе: тикшерүләр санын арттыру турында боерык.»;

5.11 пунктында:

беренче абзацта «тикшерүләр программасында каралган эшләрне» сүзләреннән соң «яисә тикшерүләр санын арттыру турында боерык чыгарылганнан» сүзләрен өстәргә;

бишенче абзацта «эшләрне башкару чорлары» сүзләреннән соң «яисә тикшерүләр санын арттыру турында боерык чыгарылганнан» сүзләрен өстәргә;

5.19 пунктының җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тикшерү уздырганда Инспекция төзүчедән, техник заказчыдан яисә төзелешне гамәлгә ашыручы заттан тикшерү предметына кагылмый торган белешмәләрне һәм документларны, шулай ук РФ Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы нигезендә формалаштырылган, әлеге Регламентның 17 нче кушымтасында китерелгән исемлеккә кертелгән, Инспекция тарафыннан әлеге документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче башка дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсына торган оешмалардан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән чорларда һәм тәртиптә алынырга мөмкин булган документларны һәм (яисә) мәгълүматларны таләп итәргә хокуклы түгел.»;

5.30 пунктның беренче абзацында «вазыйфаи зат техник тикшерү уздыруны таләп итә» сүзләрен «вазыйфаи зат төзүчедән яки техник заказчыдан техник тикшерү уздыруны таләп итә» сүзләренә алмаштырырга;

5.32 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.32. Капиталь төзелеш объектларында башкарыла торган эшләргә һәм кулланыла торган төзелеш материалларына (эшләнмәләргә) тикшеренүләр, лаборатор һәм/ки башка төрле сынаулар уздыру белән бергә туры килә торган тикшерүләрне оештырганда, Инспекциянең территориаль органнары тикшерүләр программалары кысаларында, шулай ук гамәлдәге законнарга туры китереп рәсмиләштерелгән хәбәрләр, мөрәҗәгатьләр яки башка төрле гарызнамәләр нигезендә контрольлек буенча чаралар барашыныда алынган белешмәләрнең объектив, төгәл булуын тәэмин итү һәм аларның проект чишелешләренә туры килүен, шулай ук аларның техник регламентлардагы һәм башка норматив хокукый актлардагы таләпләргә туры килүен билгеләү өчен Экспертизалар уздыруны күзәтү буенча территориаль органны җәлеп итә.

Экспертизалар уздыруны күзәтү буенча территориаль органны контрольлек чараларына җәлеп итү Экспертизалар уздыруны күзәтү буенча территориаль органның Инспекциянең структур бүлекчәләре белән үзара хезмәттәшлек итүе буенча Инспекция боерыгы белән раслана торган Тәртипкә туры китереп гамәлгә ашырыла.

Экспертизалар, тикшеренүләр, лаборатор һәм башка төрле сынаулар төзүче, техник заказчы яки төзелешне гамәлгә ашыручы зат, Инспекциянең вазыйфаи заты катнашында уздырыла.

Төзүче яки техник заказчы, шул исәптән төзелешне гамәлгә ашыручы затлар аша, тиешле экспертизаларны, тикшеренүләрне, лаборатор яисә башка төрле сынауларны уздыру өчен шартлар тудырырга бурычлы.»;

5.42 пунктка түбәндәге эчтәлекле кызыл юл өстәргә:

«Бозулар ачыкланган очракта, аларны бетерү өчен төрле чорлар таләп ителгәндә, тиешле бозу очраклары буенча аерым күрсәтмәләр төзелә.»;

5.48 пунктны түбәндәге редакциясендә бәян итәргә:

«5.48. Күрсәтмә биргән вазыйфаи зат күрсәтмәнең үтәлү чоры үтәлүен тикшереп тора.

Зарури таләпләрне бозуның ачыкланган очракларын бетерү фактын тикшерү «Капиталь төзелеш объектына тикшерү әзерләү һәм уздыру» административ процедурасына туры китереп, вазыйфаи зат тарафыннан документар яисә урынга чыгып тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла».

Әгәр тикшерү барышында зарури таләпләр бозылуның элегрәк ачыкланган бозулары юкка чыгарылган булуы билгеләнсә, тикшерү актында күрсәтмәнең үтәлүе турында тамга ясала.

Әлеге Регламентның 5.46 пунктындагы 1 пунктчада күрсәтелгән нигездә тикшерү уздырылганда, күрсәтмәнең үтәлмәве, шул исәптән күрсәтмәнең тулы күләмендә үтәлмәве ачыкланган очракта, тикшерү актында бетерлмәгән барлык җитешсезлекләр күрсәтелә, РФ КоАП 19.5 статьясының 6 өлеше буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзелә һәм яңа күрсәтмә бирелә.

Әлеге Регламентның 5.46 пунктының 1 пунктчасында күрсәтелгән нигез буенча тикшерү уздырылганда, җитешсезлекләрнең бетерелмәве, шул исәптән

җитешсезлекләрнең тулы күләмендә бетерелмәве ачыкланган очракта, тикшерү актында бетерелмәгән барлык җитешсезлекләр күрсәтелә, РФ КоАП 19.7 статьясы буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзелә.

Үтәү вакыты: әлеге Регламентның 5.46 пунктында күрсәтелгән вакыйгалар барлыкка килгән датадан соң 20 эш көненнән соңга калмыйча.

Гамәлнең нәтиҗәсе: күрсәтмәнең үтәлүен тикшерү акты; күрсәтмә үтәлмәгән очракта – күрсәтмәне үтәмәү факты буенча административ хокук бозу турында беркетмә; яңа күрсәтмә.»;

5.49 пунктының беренче абзацында «биш эш көненнән соңга калмыйча» сүзләрен төшереп калдырырга;

7 бүлекнең 7.6 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6. Әгәр дә язмача шикаятьтә шикаятьне җибәргән гражданинның фамилиясе (юридик затның аталышы) яисә җавап җибәрелергә тиешле почта адресы (электрон почта адресы) күрсәтелмәгән булса, шикаятькә җавап бирелми. Әгәр күрсәтелгән шикаятьтә хокукка каршы килә торган гамәлнең әзерләнүе, кылынуы яки кылынганлыгы турында, шулай ук аны әзерләүче, кылучы яки кылган зат турында белешмәләр булса, шикаять компетенциясенә ярашлы рәвештә дәүләт органына җибәрелергә тиеш.

Әгәр язмача шикаятьнең тексты укылышлы булмаса, шикаятькә җавап бирелми, һәм ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта шикаятьне теркәү көненнән башлап җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә, әгәр аның фамилиясе (юридик затның аталышы) һәм почта адресы укылышлы булса.

Әгәр язмача шикаять тексты шикаятьнең асылын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, шикаятькә җавап бирелми һәм ул ул карау өчен дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка алар компетенциясенә туры китереп җибәрелергә тиеш түгел, бу хакта мөрәҗәгатьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә шикаятьне җибәргән затка хәбәр ителә;

Язмача шикаятьтә аның асылы буенча элек җибәрелгән шикаятьләргә бәйле рәвештә инде берничә мәртәбә язмача җаваплар бирелгән сорау бәян ителгән булса һәм шул ук вакытта шикаятьтә яңа дәлилләр яисә шартлар китерелмәсә, Инспекция башлыгы, күрсәтелгән шикаятьнең һәм элек җибәрелгән шикаятьләрнең Инспекциягә яисә Инспекциядәге шул бер үк вазыйфаи затка җибәрелгән булуы шарты белән, чираттагы шикаятьнең нигезсез булуы һәм шушы мәсьәлә буенча мөрәҗәгать итүче белән язышуны туктату турында карар кабул итәргә хокуклы. Әлеге карар турында шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә хәбәр ителә.

Инспекциягә, 59-ФЗ номерлы федераль законның 10 статьясының 4 өлешенә туры китереп, Инспекциянең «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында җавабы урнаштырылган сорауны үз эченә алучы язмача шикаять килгән очракта, шикаятьне җибәрүче затка шикаятьне теркәүгә алган көннән соң җиде көн эчендә, шикаятьтә куелучы сорауга «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җавап урнаштырылган рәсми сайтның электрон адресы турында хәбәр ителә, бу вакытта суд карарына шикаять белдерелә торган шикаять кире кайтарылмый.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләнең асылы буенча дәүләт серен яисә федераль законда саклана торган бүтән серне тәшкил итүче белешмәләрне таратмыйча җавап биреп булмаса, шикаятьне җибәргән мөрәҗәгать итүчегә күрсәтелгән белешмәләрне таратуның мөмкин булмавына бәйле рәвештә куелган мәсьәләнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмау турында хәбәр ителә.

Цензурасыз яисә мыскыллы җөмләләрне, вазыйфаи затның, шулай ук аның гаилә әгъзаларының гомеренә, сәламәтлегенә һәм мөлкәтенә янауларны үз эченә алган язмача шикаять килгән очракта Инспекция яисә вазыйфаи зат шикаятьне анда күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавапсыз калдырырга һәм шикаятьне җибәрүче мөрәҗәгать итүчегә хокук белән исәпләшмәүнең ярамаганлыгы турында хәбәр итәргә хокуклы.

Суд карары шикаять кылына торган шикаять теркәлгән көненнән башлап җиде көн дәвамында, әлеге суд карарын шикаять кылу тәртибен аңлатып, шикаятьне җибәрүче мөрәҗәгать итүчегә кире җибәрелә.

Әгәр шикаятьтә күтәрелгән мәсьәләләрнең асылы буенча җавап бирү мөмкинлеге булмаган сәбәпләр алга таба бетерелсә, мөрәҗәгать итүче шикаятьне күзәтчелек органына яңадан җибәрергә хокуклы.»;

Регламентка кушымталарда:

2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 2 нче кушымта

**Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясенең Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәве буенча блок-схема**



Документар тикшерү

Вазыйфаи зат тарафыннан Инспекциядә булган документларны карау;
кирәк булганда, тикшерелә торган зат адресына тапшырылган документларның билгеләнгән таләпләргә җавап бирмәве турында хат (дәлилле гарызнамә) юллау; гарызнамәгә тикшерү уздыру турында күрсәтмә күчермәсе кушып куела;
вазыйфаи зат тарафыннан тапшырылган документларны карау (20 эш көненнән артык түгел)

Зарурлык булганда, урынга чыгып тикшерү уздыру турында карар кабул

Урынга чыгып тикшерү

Вазыйфаи затның күзәтчелек эше материаллары, объектның проект документациясе белән танышуы;
объектка килгәч – хезмәт таныклыгын күрсәтү, тикшерелә торган зат вәкилен тикшерү уздыру турында күрсәтмә, урынга чыгып тикшерүнең максатлары, бурычлары, нигезләре, контрольлек чараларының төрләре һәм күләме, тикшерү уздыруның чорлары һәм шартлары белән таныштыру (20 эш көненнән артык түгел)

Күрсәтмә нигезендә урынга чыгып тикшерү уздыру

Тикшерүләрнең нәтиҗәләрен рәсмиләштерү
(тикшерү актын рәсмиләштерү, уздырылган тикшерү турында язуларны тикшерүләрне исәпкә алу журналына, гомуми һәм (яисә) махсус журналларга теркәү, тиешле мәгълүматларны тикшерүләрнең

Тикшерелә торган затны тикшерү акты (ачыкланган бозуларны бетерү турында күрсәтмә) белән таныштыру (тикшерү тәмамлангач турыдан-туры)

Тикшерү акты күчермәсен прокуратура органына җибәрү (прокуратура органы белән килешенгәнлек булганда) (тикшерү тәмамлангач биш эш көне эчендә)

Төзелеше тәмамланган капиталь төзелеш объектына тикшерү уздыру (20 эш көненнән артык түгел)

Ярашлылык турында бәяләмә бирү яисә ярашлылык турында бәяләмә бирүдән баш тарту турында карар

Зарури таләпләр бозылу очраклары ачыкланганда

Бозуларны бетерү буенча чаралар күрү

Зарури таләпләр бозылу очракларын бетерү турында күрсәтмә төзү, ул тикшерү актына кушымта булып тора

Административ хокук бозу турында беркетмә төзү, аның РФ КоАП билгеләнгән тәртиптә аның каралуын тәэмин итү

Үзкөйләнешле оешма әгъзасы тарафыннан хокук бозылуны ачыклаган очракта: ҮКОда ачыкланган бозулар турында

Зарури таләпләр бозылу очракларын бетерү буенча тикшерү уздыру (әлеге Регламентның 5.46 пунктында күрсәтелгән вакыйгалар башланган датадан соң 20 эш көненнән артык түгел)";

5 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 5 нче кушымта

(Типик рәвеше)

**ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУ ПРОГРАММАСЫ**

Эш №__________ Нөсхә ___________

1. Төзүче, техник заказчы_____________________________________________
(төзүченең, техник заказчының

_________________________________________________________________
атамасы (техник заказчы булганда), дәүләт теркәвенә алу турында
_________________________________________________________________
таныклык номеры һәм бирелү датасы, ОГРН, ИНН,
_________________________________________________________________
почта реквизитлары, телефон/факс - юридик затларга; фамилия, исем,
_________________________________________________________________
ата исеме - төзүченеке яисә техник заказчыныкы, паспорт белешмәләре,
_________________________________________________________________
яшәгән урыны, телефон/факс - физик затларга)

2. Капиталь төзелеш объекты
_________________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының атамасы,
_________________________________________________________________
проект документациясенә туры китереп, кыскача проект сыйфатламалары, төзелеш, үзгәртеп кору этабын тасвирлау,
_________________________________________________________________
мәдәни мирас объектларын саклау буенча мондый объектның конструктив һәм ышанычлы һәм куркынычсыз булуы турында башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләр, әгәр рөхсәт төзелеш, үзгәртеп кору этабына бирелсә)

3. Капиталь төзелеш объектының адресы (урнашкан урыны)
_________________________________________________________________
_________________________________________________________________
(капиталь төзелеш объектының почта яисә төзелә торган адресы)

4. Капиталь төзелеш объектын төзүгә рөхсәт

___________________________________________________________________________

(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән, гамәлдә булу чоры)

5. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 49 статьясы таләпләренә туры китереп, проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе (типик проект документациясен яисә аның типик проект документациясе реестрына кертелгән модификациясен куллануны күрсәтү)

___________________________________________________________________________

(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

___________________________________________________________________________

6. Проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы буенча уңай бәяләмә, әгәр капиталь төзелеш объектының проект документациясе дәүләт экология экспертизасын узарга тиешле булса

___________________________________________________________________________

(номеры һәм бирелү датасы, кем тарафыннан бирелгән)

___________________________________________________________________________

_________________________________________________________________

7. Төзүне, үзгәртеп коруны, мәдәни мирас объектын саклау буенча аның конструктив һәм ышанычлы һәм куркынычсыз булуына кагылышлы башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләрне башлау

___________________________________________________________________________

(эшләрне башлау датасы)

8. Төзүне, үзгәртеп коруны, мәдәни мирас объектын саклау буенча аның конструктив һәм ышанычлы һәм куркынычсыз булуына кагылышлы башка сыйфатламаларына кагыла торган эшләрне тәмамлау

___________________________________________________________________________

(эшләрне тәмамлау датасы)

9. Тикшерүләр уздыру программасына үзгәрешләр кертү өчен нигезләр

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(үзгәрешләр кертелгән очракта тутырыла)

10) Төзелә, үзгәртеп корыла торган капиталь төзелеш объектының куркыныч категориясе

___________________________________________________________________________

___________________________________________________________________________

(бик куркыныч/шактый куркыныч/уртача куркыныч)

## ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРУ ПРОГРАММАСЫ

| № п/п | Төзелешне оештыру проектына туры китереп | Һәр тикшерүнең | Һәр тикшерүне уздыру | Һәр тикшерүне уздыру буенча дәүләт | Тикшерүләр программасында каралган, | Тикшерүләр программасында каралганча тикшерүләрне |
|---|---|---|---|---|---|---|

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | билгеләнә торган, тикшерелергә тиешле эшләр исемлеге | предметы | ның якынча датасы | төзелеш күзәтчелеге органы вазыйфаи затының чама белән сарыф ителгән вакыты | тикшерүләрне уздырганда тапшырылырга тиешле документлар | уздырганда зарури катнашырга тиешле вазыйфаи затлар яисә төзүченең, техник заказчының хезмәткәрләре яки төзүче яки техник заказчы белән төзелгән шартнамә нигезендә төзелешне гамәлгә ашыручы затлар |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 |
| | | | | | | |

____________________ ____________________________ ________________________

(имза) (тулы имза) (вазыйфа)

Килештерелде:

________________________________ ___________ ____________________

(объект буенча дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру өчен җаваплы зат билгеләү турында боерык үтәлеше өчен җаваплы буларак билгеләнгән зат (имза) (тулы имза)

Тикшерүләр уздыру программасының бер нөсхәсен алдым:

(төзүченең яисә техник заказчының вәкиле тарафыннан вәкиллек турында документ реквизитларын күрсәтеп тутырыла)

20____ елның «___» ____________.»;

түбәндәге эчтәлекле 17 нче кушымта өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт төзелеш күзәтчелеге инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт төзелеш күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 17 нче кушымта

ТИКШЕРҮЛӘР УЗДЫРГАНДА ВЕДОМСТВОАРА МӘГЪЛҮМАТИ

# ХЕЗМӘТТӘШЛЕК КЫСАЛАРЫНДА ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ ТӨЗЕЛЕШ КҮЗӘТЧЕЛЕГЕ ИНСПЕКЦИЯСЕ ТАРАФЫННАН ДОКУМЕНТЛАРҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАР БЕЛӘН ЭШ ИТҮЧЕ БАШКА ДӘҮЛӘТ ОРГАННАРЫННАН, ҖИРЛЕ ҮЗИДАРӘ ОРГАННАРЫННАН ЯИСӘ ОЕШМАЛАРДАН СОРАТЫЛА ТОРГАН ӘЛЕГЕ ДОКУМЕНТЛАРНЫҢ ҺӘМ (ЯИСӘ) МӘГЪЛҮМАТЛАРНЫҢ ИСЕМЛЕГЕ

| Соралучы документның һәм (яисә) мәгълүматның аталышы | Сорала торган документ һәм (яисә) мәгълүмат белән эш итүче дәүләт органы, җирле үзидарә органы |
|---|---|
| Төзелешкә рөхсәт<br>Объектны эксплуатациягә кертүгә рөхсәт<br>Проект документациясенә уңай экспертиза бәяләмәсе<br>Капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору буенча рөхсәт ителгән чик параметрлардан чигенүгә рөхсәттән белешмәләр | Җирле үзидарә органнары<br><br>Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм ТКХ министрлыгы<br><br>Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Россия Федерациясе халыкларының мәдәни мирас объектларын (тарихи һәм мәдәни ядкәрләрен) саклау эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензияләр реестрыннан белешмәләр | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы |
| Федераль мөлкәт реестрыннан өземтә | Росимущество |
| Эшчәнлек (эшләрнең, хезмәтләрнең) төрләренең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләрендәге һәм гигиена нормативларындагы таләпләргә туры килүе (туры килмәве) турында санитар-эпидемиология бәяләмәләреннән белешмәләр<br><br>Проект документациясенең дәүләт санитар-эпидемиология кагыйдәләрендәге һәм гигиена нормативларындагы таләпләргә туры килүе (туры килмәве) турында санитар-эпидемиология бәяләмәләреннән белешмәләр | Роспотребнадзор |
| Зыянлы (пычратучы) матдә ташландыкларының чик дәрәҗә мөмкин булган расланган нормативлары булуы турында мәгълүмат, зыянлы (пычратучы) матдә ташландыкларының вакытлыча килештерелгән билгеләнгән нормативлары турында мәгълүмат<br><br>Проект документациясенә дәүләт экология экспертизасы бәяләмәсе турында мәгълүмат | Росприроднадзор |

| | |
|---|---|
| Ярашлылык турында декларацияләр реестрыннан белешмәләр | Росаккредитация |
| Инженерлык эзләнүләре, архитектура-төзелеш проектлары, капиталь төзелеш объектларын төзү, үзгәртеп кору, капиталь ремонтлау өлкәсендә үзкөйләнешле оешмалар реестрыннан өземтә | Ростехнадзор |
| Салым түләүчеләрнең бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр<br><br>Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр<br><br>Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан белешмәләр<br><br>Кече һәм урта эшкуарлык субъектларының бердәм реестрыннан белешмәләр | Россиянең ФСХ |
| Транспорт чаралары һәм әлеге транспорт чаралары теркәлгән затлар турында белешмәләр<br><br>Чит ил гражданинын яки гражданлыгы булмаган затны тору урыны буенча исәпкә кую турында белешмәләр<br><br>Чит ил гражданинын яисә гражданлыгы булмаган затны яшәү урыны буенча теркәүгә алу турында белешмәләр<br><br>Россия Федерациясе гражданинын яшәгән урыны буенча теркәүгә алу турында белешмәләр<br><br>Россия Федерациясе гражданинын тору урыны буенча теркәүгә алу турында белешмәләр | Россия ЭЭМ |
| Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объекты турында өземтә<br><br>Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрыннан күчемсез мөлкәт объектына хокуклар күчүе турында өземтә | Росреестр»; |